| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ГЛАВА КУЛЬБАЕВО-МАРАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛБАЙ-МОРАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Колбай-Мораса ав. **КАРАР**

«01» ноябрь 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Көрнәле-Әмзә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Колбай-Мораса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 13 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка Үзәк урамы буенча 10нчы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Көрнәле-Әмзә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2024 елда Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Көрнәле-Әмзә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 5000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Көрнәле-Әмзә авылы территориясен төзекләндерү;
- парк зонасын төзекләндерү эше
- зират территориясен төзекләндерү, хуҗалык инвентарын саклау өчен йорт сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Насыйбуллин